РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 13** **2017 елның 24 гыйнвары**

**«Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, күчемсез милек хокукына ия булучыларның һәм күчемсез милек объектларына ия булу, алардан файдалану, эш итү хокукларын алырга теләгән затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатларында Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Үзгәрешләр таблицасы нигезендә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 мартындагы 10 номерлы карары белән расланган «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең график өлешенә, үзгәрешләр кертү:

| № | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Гамәлдәге зона | Билгеләнүче зона |
|---|---|---|---|
| 1 | 16:30:020402:386 | ОД-1 | Ж-1 |
| 2 | 16:30:020402:521 | ОД-1 | Ж-1 |
| 3 | 16:30:020402:517 | ОД-1 | Ж-1 |
| 4 | 16:30:020402 (ызанлау планы нигезендә) | Ж-1 | ИТ-1 |
| 5 | 16:30:021302:168 | Ж-1 | ИТ-1 |

2. «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Борок авылында кертелгән үзгәрешләр белән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасын (1 нче кушымта) һәм территорияләрне файдалану буенча махсус шартлары булган зоналар картасын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

4. «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Россия Федерациясенең Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин